**III ЧАКЫРЫЛЫШ**
**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БӨГЕЛМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**«ВЯЗОВКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»**
**МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**КЫРЫГЫНЧЫ СЕССИЯ**

**1нче КАРАР**

Вязовка авылы 06.08.2019 ел

**Бөгелмә муниципаль районы**
**Вязовка авыл җирлеге Советының**
**2019 елның 20 маенда булып узган**
**38нче сессиясендә кабул иткән**
**“Татарстан Республикасы**
**Бөгелмә муниципаль районы**
**“Вязовка авыл җирлеге”**
**муниципаль берәмлегендә**
**гавами тыңлауларны оештыру**
**һәм үткәрү тәртибе турында”гы**
**1нче карарга**
**үзгәрешләр кертү турында**

Законнарга туры китерү максатында, Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы Вязовка авыл җирлеге Уставына таянып,

**Вязовка авыл җирлеге Советы**

**КАРАР БИРДЕ:**

Бөгелмә муниципаль районы Вязовка авыл җирлеге Советының 2019 елның 20 маенда булып узган 38нче сессиясендә кабул иткән “Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы “Вязовка авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турында”гы 1нче карарга түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1. 2нче бүлектә:

1.1. 2.2 пунктның 1нче аспунктын яңа басмада бәян итәргә:
«1) “Вязовка авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге устав проекты, шулай ук әлеге Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турындагы хокукый-норматив акт проекты, муниципаль берәмлек проектына үзгәрешләр, әлеге уставны шушы

хокукый-норматив актларга туры китерү максатыннан, Россия Федерациясе Конституциясе, федераль законнар, Россия Федерациясе субъекты конституциясе (уставы) яки законнарының нигезләмәләрен төгәл кабатлау формасында кертелү очракларыннан тыш;

1.2. 2.2 пунктның 3нче аспунктын яңа басмада бәян итәргә:
«3) Муниципаль берәмлекне үзгәртеп кору турындагы сораулар, 2003 елның 6 октябрендә кабул ителгән №131-ФЗ Федераль законының 13нче маддәсенә туры китереп, муниципаль берәмлекне үзгәртеп кору өчен тавыш бирү юлы белән яки гражданнар җыеннарында белдерелгән тәртиптә, халыкның ризалыгын алу таләп ителгән очраклардан тыш».
2. Әлеге карар күмәк мәгълүмат чараларында рәсми төстә басылып чыккан көннән үз көченә керә.
3. Әлеге карарга контрольлек итүне үз өстемдә калдырам.

**“Вязовка авыл җирлеге”**
**муниципаль берәмлеге башлыгы В.Н.Соколов**